**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы**

**№** 1 **дата** 10.02.2020 **ел.**

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге

КАРАР БИРДЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

**2.** Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

- карьерларны эшкәртү (киң таралган файдалы казылмалар чыгару) өчен җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән һәм файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата - 0,03% ;

- 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата - 0,05%;

- кунакханәләрне урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,1% ;

- 0,15% - торак фонды белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата (торак фондына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә яисә торак тезелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) - 0,15%;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган җир кишәрлекләренә карата - 0,15%;,

-эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата - 0,3%";

- торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш) - 0,3%;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составындагы җирләргә карата - 0,3%;

- оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,3%;

-мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать, дин, стационар һәм палаткалы туристлык-сәламәтләндерү

һәм спорт лагерьларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,4%;

-җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать корылмалары, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-телек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,0% ;

- сәүдә, җәмәгать туклануы һәм кенкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру ечен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,2% ;

- авыл хуҗалыгы җитештерүе ечен файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы файдалануы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,5% ;

- гаражлар һәм автостоянкалар урнаштыру ечен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,5% ;

- башка җир кишәрлекләренә карата - 1,5%.

**3**. Түбәндәге категория салым түләүчеләрне җир салымын түләүдән азат итәргә:

1) гражданнар каберлекләре, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары, чишмәләр, су башнялары, скважиналар, һәйкәлләр, пляжлар биләгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр;

2) 90 һәм аннан да күбрәк яшькә җиткән гражданнар;

3) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, сугышта катнашучылар;

4) Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә бирелгән җирләр буенча күпбалалы гаиләләр.

**4.** Календарь елы салым чоры дип таныла. Календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм еченче кварталын салым түләүче оешмалар ечен хисап чоры дип таныргa.

5. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң узган хисап кварталыннан соң килгән икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, җир кишәрлегенең кадастр бәясе ¼ процент елешенең тиешле салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 5 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

6. Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз кеченә керә.

7. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 26.11.2019 ел, 26 ноябрендәге 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

**Минзәлә муниципаль районы**
**Воровский ис. авыл җирлеге Башлыгы,**
**Воровский ис. авыл җирлеге Советы рәисе** **С.Г. Юдин.**